КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 7 март г.Казань № 138

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты мәсьәләләре» 2017 ел, 15 декабрь, 996 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты мәсьәләләре» 2017 ел, 15 декабрь, 996 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 26 февраль, 110 нчы, 2018 ел, 7 май, 327 нче, 2018 ел, 30 июль, 614 нче, 2018 ел, 29 декабрь, 1288 нче, 2019 ел, 23 апрель, 329 нчы, 2019 ел, 18 декабрь, 1165 нче, 2020 ел, 11 февраль, 87 нче, 2020 ел, 15 май, 392 нче, 2020 ел, 8 август, 666 нчы, 2021 ел, 17 июнь, 467 нче, 2021 ел, 11 август, 700 нче, 2021 ел, 6 сентябрь, 817 нче, 2021 ел, 27 ноябрь, 1140 нчы, 2021 ел, 9 декабрь, 1209 нчы, 2022 ел, 7 март, 202 нче, 2022 ел, 17 март, 244 нче, 2022 ел, 29 апрель, 402 нче, 2022 ел, 22 сентябрь, 1029 нчы, 2022 ел, 11 ноябрь, 1196 нчы, 2023 ел, 6 март, 214 нче, 2023 ел, 21 март, 306 нчы, 2023 ел, 17 июль, 851 нче, 2023 ел, 10 октябрь, 1284 нче, 2023 ел, 30 ноябрь, 1536 нчы, 2024 ел, 18 март, 155 нче, 2024 ел, 14 июнь, 427 нче, 2024 ел, 15 ноябрь, 1011 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4.1 пунктта:

4.1.11 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.1.11. Федераль әһәмияттәге махсус сакланылучы табигать территорияләреннән, шулай ук эчке суларның Россия Федерациясе Кызыл китабына кертелгән

су биологик ресурсларыннан, балыкларның анадром һәм катадром төрләреннән, балыкларның чик буе төрләреннән тыш, сәнәгать, һәвәскәрлек балыкчылыгын оештыру һәм җайга салу; балык тоту участокларын бирү;»;

4.1.29 һәм 4.1.30 пунктчаларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.1.29. Сәнәгать балык тотуны гамәлгә ашыру өчен эчке су объектларында су биологик ресурсларын чыгару (тоту) квоталарын бүлү;

4.1.30. Түбәндәгеләрне төзү хокукын сату буенча электрон формада аукционнар оештыру һәм уздыру:

эчке су объектларында сәнәгать балык тотуын гамәлгә ашыру өчен квота өлешен беркетү турында шартнамә, балыкларның анадром һәм ката-дром төрләреннән тыш;

эчке су объектларында сәнәгать балык тотуын гамәлгә ашыру өчен су биологик ресурсларыннан файдалану шартнамәсе, балыкларның анадром һәм ката-дром төрләреннән тыш;

эчке су объектларының су биологик ресурсларына карата сәнәгать балык тоту урыныннан файдалану шартнамәсе, балыкларның анадром һәм ката-дром төрләреннән тыш;»;

4.1.31 пунктчада «һәм спорт» сүзләрен төшереп калдырырга;

4.1.32 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.1.32. Йомгак:

эчке су объектларында сәнәгать балык тотуын гамәлгә ашыру өчен квота өлешен беркетү турында шартнамә, балыкларның анадром һәм ката-дром төрләреннән тыш;

эчке су объектларында сәнәгать балык тотуын гамәлгә ашыру өчен су биологик ресурсларыннан файдалану шартнамәсе, балыкларның анадром һәм ката-дром төрләреннән тыш;

эчке су объектларының су биологик ресурсларына карата сәнәгать балык тоту урыныннан файдалану шартнамәсе, балыкларның анадром һәм ката-дром төрләреннән тыш;».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин